**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21.10.2024 № 1253

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәлешен тәэмин итүче оешмалар исемлеген раслау турында

“Гражданнар оборонасы турында" 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, гражданнар оборонасы буенча чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау планы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәлешен тәэмин итүче Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы оешмалары исемлеген (1 нче кушымта) расларга.
2. Оешмалар җитәкчеләренә, расланган исемлек нигезендә, үз вәкаләтләре чикләрендә һәм "гражданнар оборонасы турында" 12.02.1998 ел, № 28-ФЗ Федераль законның 9 статьясының 1 пунктында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы буенча чаралар башкаруны оештыру чараларын күрергә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә калдырырга.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин